**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 160-74 17 января 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 72 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Түйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында
(31.10.2014 № 97, от 09.03.2016 № 28-10, от 29.11.2016 №47-23, от 11.09.2017 № 68-32, от 16.07.2018 № 104-49, от 19.03.2019 № 132-63 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 өлеше, 32, 33 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 2019 елның 16 декабрендәге «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

Туйкә авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 72 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Түйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (31.10.2014 № 97, от 09.03.2016 № 28-10, от 29.11.2016 №47-23, от 11.09.2017 № 68-32, от 16.07.2018 № 104-49, от 19.03.2019 № 132-63 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- мәйданы 18501,0 кв. м. булган, 16:02:060303:375, 16:02:060303:376 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авыл җирлеге адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны СН2 махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасыннан һәм авыл хуҗалыгы җирләре СХУ җирләреннән авыл хуҗалыгы СХ1 билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә;
- мәйданы 4784,0 кв.м. булган, 16:02:060301:223 кадастр номерлы,Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авылы, Ленин урамы, 22 йорт

адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны Ж1 шәхси торак төзелеше зонасыннан СХ1авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//. Веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис Р.Р.Закирова